ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 16.12.2015

с. Коргуза

КАРАР 2

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Карагуҗа авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләре буенча уртак инициативасын күрсәтергә:

«2015 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешәсезме:

- Карагуҗа авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК"

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы В.В.Карасёв